РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА АЗНАКАЕВО
АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АЗНАКАЙ ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ул. Ленина, д.14, г. Азнакаево, 423330 Ленин урамы, 14 йорт, Азнакай шәһәре, 423330

Тел./факс(885592)7-15-50,7-00-37; E-mail:aznakay@tatar.ru, adm-aznakay@mail.ru; http://aznakayevo.tatarstan.ru/

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

10.10.2024 ел. № 34

Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Башкарма комитетының 2019 елның 26 февралендәге 05 номерлы «Муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең административ регламентлары турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында (05.08.2019 №26, 11.11.2019 №36, 24.04.2020 №14, 14.09.2020 №24, 01.12.2020 №28, 03.02.2021 №05, 07.06.2021 №16, 28.07.2021 №23, 21.09.2021 №29, 15.12.2021 №38, 26.09.2022 №30, 29.11.2023 №57, 22.05.2024 №22 карарлар редакциясендә)

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 13 апрелендәге 242 номерлы «Дәүләт йөкләмәсе (заказы) урнаштырыла торган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган социаль әһәмиятле дәүләт хезмәтләре, хезмәтләр күрсәтүгә күчү чаралары планын раслау турында»гы карары, электрон рәвештә Татарстан Республикасы Икътисад Министрлыгының 2024 елның 08 августындагы 02-51/5035 номерлы хатларын үтәү йөзеннән, карар бирә:

1. Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Башкарма комитетының 2019 елның 26 февралендәге 05 номерлы «Муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең административ регламентлары турында»гы карарына (05.08.2019 №26, 11.11.2019 №36, 24.04.2020 №14, 14.09.2020 №24, 01.12.2020 №28, 03.02.2021 №05, 07.06.2021 №16, 28.07.2021 №23, 21.09.2021 №29, 15.12.2021 №38, 26.09.2022 №30, 29.11.2023 №57, 22.05.2024 №22 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.Хосусыйлаштырылган торак урыннарын муниципаль милеккә кабул итү буенча

муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) «Республика порталы» сүзләре алдыннан тиешле килештә «Бердәм портал,» сүзләрен тиешле килештә өстәргә;

б) 2.6.1 пунктының 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) граждан хәле актларын теркәү турында белешмәләр - ЗАГС органнары;»;

в) 2.6.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 6 һәм 7 пунктчаларны өстәргә:
«6) яшәү урыны буенча теркәлү турында белешмә - Башкарма комитет;
7) опека һәм попечительлек органын торак урынны муниципаль милеккә түләүсез тапшыруга рөхсәт бирү (әгәр хосусыйлаштыруда балигъ булмаган балалар катнашса) - Башкарма комитет.»;
г) 2.14 бүлекне түбәндәге эчтәлекле 9 пунктчаны өстәргә:
«9) муниципаль хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр тарафыннан, инвалидларга алар хезмәт күрсәтүләргә башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә комачаулаучы каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү.»;
д) №3 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Муниципаль хезмәт нәтиҗәсен курсәтүегезне сорыйм:

☐ Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталының шәхси кабинетында;

☐ Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталының шәхси кабинетында;

☐ Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә;

☐ Башкарма комитетта».

1.2. Хезмәт урыны наем шартнамәләре буенча муниципаль торак фондында гражданнарга торак урыннары бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
а)административ регламентның текстьы буенча «Республика порталы» сүзләре алдыннан тиешле килештә «Бердәм портал» сүзләрен тиешле килештә өстәргә;
г) 2.14 бүлекне түбәндәге эчтәлекле 9 пунктчаны өстәргә:
«9) муниципаль хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр тарафыннан, инвалидларга алар хезмәт күрсәтүләргә башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә комачаулаучы каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү.»;
д) №4 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Муниципаль хезмәт нәтиҗәсен курсәтүегезне сорыйм:

☐ Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталының шәхси кабинетында;

☐ Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталының шәхси кабинетында;

☐ Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә;

☐ Башкарма комитетта».

1.3. Хезмәт урыны наем шартнамәләре буенча муниципаль торак фондында гражданнарга торак урыннары бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а)административ регламентның текстлы буенча «Республика порталы» сүзләре алдыннан тиешле килештә «Бердәм портал,» сүзләрен тиешле килештә өстәргә;

б) 2.5.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 5 пунктчаны өстәргә:

«5) хокуклары Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрында теркәлмәгән күчемсез мөлкәт объектларына хокук билгели торган документлар.»;

в)2.8.2 пунктына түбәндәге эчтәлекле 8 пунктчаны өстәргә:

«8) муниципаль торак фондында ирекле хезмәт урыны булмау.»;

г) 4.2 бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 4.2.5 пунктны өстәргә:

«4.2.5. Контроль тикшерүләр планлы (җирле үзидарә органы эшенең ярты еллык яисә еллык планнары нигезендә гамәлгә ашырылырга) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр уздырганда муниципаль хезмәт күрсәтүгә (комплекслы тикшерүләргә) бәйле барлык мәсьәләләр яисә мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча каралырга мөмкин.»;

д) №3 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәт нәтиҗәсен курсәтүегезне сорыйм:

☐ Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталының шәхси кабинетында;

☐ Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталының шәхси кабинетында;

☐ Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә;

☐ Башкарма комитетта».

1.4. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегенең махсуслаштырылган торак фонды составына кертү һәм торак урыннарын төшереп калдыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) административ регламентның тексты буенча «Республика порталы» сүзләре алдыннан тиешле килештә «Бердәм портал,» сүзләрен тиешле килештә өстәргә;

б) 1.8 пунктына түбәндәге эчтәлекле 7 пунктчаны өстәргә:

«аларда яшәүче гражданнар булмаганда.»;

в) 4 нче һәм 5 нче кушымталарны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәт нәтиҗәсен курсәтүегезне сорыйм:

☐ Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталының шәхси кабинетында;

☐ Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталының шәхси кабинетында;

☐ Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр

күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә;

☐ Башкарма комитетта».

1.5.Белешмәләр (өземтәләр) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) административ регламентның тексты буенча «Республика порталы» сүзләре алдыннан тиешле килештә «Бердәм портал,» сүзләрен тиешле килештә өстәргә;

б) 4 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәт нәтиҗәсен курсәтүегезне сорыйм:

☐ Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталының шәхси кабинетында;

☐ Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталының шәхси кабинетында;

☐ Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә;

☐ Башкарма комитетта».

1.6 Юл билгеләрендә индивидуаль проектлау билгеләрен урнаштыруны килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) административ регламентның тексты буенча «Республика порталы» сүзләре алдыннан тиешле килештә «Бердәм портал,» сүзләрен тиешле килештә өстәргә;

б) 2.5.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 5 пунктчаны өстәргә:

5) юл билгеләре милекчеләре тарафыннан (урамнарны яктырту баганаларында индивидуаль проектлауның мәгълүмати билгеләрен (мәгълүмат модуле белән) урнаштырганда һәм аларда электр җир өсте транспортының контакт челтәрләре беркетүләре урнаштырылганда) килештерүләр»;

в) 2.8 бүлеген яңа редакциядә бәян итәргә:

"2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору яисә күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

2.8.1. Хезмәтләр күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр исемлеге:

1) индивидуаль проектлауның мәгълүмат билгеләрендәге тышкы кыяфәтне, язуларны үзгәртү (мәгълүмат модуле белән);

2) индивидуаль проектлау мәгълүмат билгеләренең (мәгълүмат модуле белән) аларны урнаштыру буенча техник шартларга туры килмәве.

2.8.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр исемлеге:

1) мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларның әлеге регламентта билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

2) мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт алуга хокукы булмау;

3) мөрәҗәгать итүче инициативасы буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә гаризаны чакыртып алу;

4) тапшырылган документларның ГОСТ Р-52289-2019, ГОСТ Р-52290-2004 таләпләренә туры килмәве;

5) күрсәтелгән юнәлешнең һәм объектка кадәрге ераклыкның чынбарлык юл билгесе белән туры килмәве;

6) юл билгесенең урнашу урыны Актүбә бистәсе территориясенә керми;

7) күрсәтелгән гаризада (4 нче кушымтада) индивидуаль проектлау мәгълүмат билгеләрен урнаштыруның максатсызлыгы турында район юл хәрәкәте иминлеге комиссиясе утырышы карары булуы.

2.8.3. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр исемлеге төгәл була.

2.8.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза Бердәм порталда, Республика порталында, шулай ук муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында бастырылган муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты һәм тәртибе турындагы мәгълүмат нигезендә бирелгән очракта муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту тыела.»;

г) 4.2 бүлеген яңа редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгы һәм сыйфаты буенча планлы һәм планнан тыш тикшерүләрне гамәлгә ашыру тәртибе һәм чоры, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшереп тору тәртибе һәм рәвешләре

Контроль тикшерүләр планлы (җирле үзидарә органы эшенең ярты еллык яисә еллык планнары нигезендә гамәлгә ашырылырга) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр уздырганда муниципаль хезмәт күрсәтүгә (комплекслы тикшерүләргә) бәйле барлык мәсьәләләр дә каралырга мөмкин.

д) 4 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәт нәтиҗәсен курсәтүегезне сорыйм:

☐ Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталының шәхси кабинетында;

☐ Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталының шәхси кабинетында;

☐ Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә;

☐ Башкарма комитетта».

1.7. Муниципаль милектәге җирләрдә стационар булмаган сәүдә объектларын аукцион үткәрмичә урнаштыруга шартнамә төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) административ регламентның текстына буенча «Республика порталы» сүзләре алдыннан тиешле килештә «Бердәм портал,» сүзләрен тиешле килештә өстәргә;

б) 4 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәт нәтиҗәсен курсәтүегезне сорыйм:

☐ Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталының шәхси кабинетында;

☐ Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталының шәхси кабинетында;

☐ Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр

күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә;

☐ Башкарма комитетта».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Э.Ә. Габдрахманов